**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

---

**2023 елның 23 октябре** **110-РС номер**

# КАРАР

**«Лаеш муниципаль районында халык дружиналары турында» 2014 елның 30 июнендәге 23 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (үзләштерүгә) һәм террорчылыкны финанслауга каршы тору турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022елның 28 июнендәге 219-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» Федераль законга җәмәгать тәртибен саклау өлкәсендә хокук мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 31 декабрендәге 497-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Лаеш муниципаль районы Советы **карар кабул итте**:

1. «Лаеш муниципаль районында халык дружиналары турында» 2014 елның 30 июнендәге 23 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык һәм хокук тәртибе комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык - муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

*Татарстан Республикасы*
*Лаеш муниципаль районы Советының*
*«23» октябрендәге 2023-110-РС номерлы*
*карарына кушымта*

«Лаеш муниципаль районында халык дружиналары турында» 2014 елның 30 июнендәге 23 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә

**1) 4 бүлекнең 2 пунктының 4 пунктчасы, 3 бүлекнең 8 пунктының 4 пунктчасы**

«БМОның VII Уставы, БМО Куркынычсызлык советы яисә БМО Куркынычсызлык советының махсус төзелгән карарларында, террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән бәйле яисә массакүләм юк итү коралын таратуга бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында төзелә торган» сүзләрен өстәргә;

**2) 4 бүлекнең 2 пунктының 8 пунктчасы, II бүлекнең 8 пунктчасының 8 пунктчасы**

«моңа кадәр булганнарга» сүзен «моңа кадәр булучылар» сүзенә алмаштырырга, «кылынган» сүзе алдыннан «алдан ниятләп» сүзен өстәргә.